**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская,
дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

“28” апрель 2023 ел. № 175

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча Территориаль өч яклы комиссия төзү турында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 35 статьясы һәм «Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында» 2004 елның 26 июлендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, социаль партнерлык системасын камилләштерү һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча Территориаль өч яклы комиссия төзергә.
2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча Территориаль өч яклы комиссиясе турында Нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча Территориаль өч яклы комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
4. Татарстан Республикасы Әтнә район Башкарма комитеты җитәкчесе Каюмов Айрат Фәниль улын Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча Территориаль өч яклы комиссия координаторы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының http://atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әтнә муниципаль районы башлыгы -
Әтнә район Советы рәисе: Г.Г.Хәкимов

1 нче Кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә район Советының
28 апрель 2023 №175 карарына

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча Территориаль өч яклы комиссиясе турында Нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча Территориаль өч яклы комиссия (алга таба – Комиссия) гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә территориаль һөнәри берлекләр һәм аларның берләшмәләре, эш бирүчеләрнең Территориаль берләшмәләре, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкилләренең үзара килешүе нигезендә формалаштырыла (алга таба – Комиссия яклары).

1.2. Комиссия эшчәнлегенең хокукый нигезен Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында» 26.07.2004 № 42-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы һәм әлеге Нигезләмә тәшкил итә.

2. Комиссияне формалаштыру принциплары һәм тәртибе

2.1. Комиссия комиссия вәкилләренең комиссия эшчәнлегендә катнашу иреклелеге, якларның тигезлеге һәм тигез хокуклылыгы, аларның вәкилләренең вәкаләтлелеге, комиссиядә үз вәкилләренең шәхси составын билгеләгәндә комиссия якларының мөстәкыйльлеге һәм бәйсезлеге принциплары нигезендә формалаша.

Комиссиянең сан һәм персональ составы Татарстан Республикасының Әтнә район Советы тарафыннан раслана.

Территориаль һөнәри берлекләр һәм аларның берләшмәләре, эш бирүчеләрнең Территориаль берләшмәләре вәкилләр исемлеген комиссия составына җибәрә.

Комиссия яклары вәкилләре комиссия әгъзалары булып тора. Комиссиянең һәр ягыннан комиссия әгъзалары саны 10 кешедән артмаска тиеш.

2.2. Территориаль һөнәри берлекләр һәм аларның берләшмәләре, эш бирүчеләрнең Территориаль берләшмәләре вәкилләрен комиссиядә раслау һәм алыштыру әлеге берләшмәләр органнары карары белән башкарыла.

2.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкилләрен раслау һәм алыштыру Әтнә район Советы карары белән башкарыла.

## 3. Комиссиянең максатлары һәм бурычлары

3.1. Комиссиянең төп максатлары булып торалар:

- социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен көйләү һәм якларның социаль-икътисади мәнфәгатьләрен килештерү;
- социаль партнерлык системасын үстерү;
- коллектив хезмәт бәхәсләрен (конфликтларын) җайга салуга ярдәм итү.

3.2. Комиссиянең төп бурычлары булып торалар:

- коллектив сөйләшүләр алып бару һәм территориаль килешү проектын әзерләү;
- территориаль килешүне үтәү барышында барлыкка килгән комиссия яклары инициативасы буенча мәсьәләләрне карау;
- территориаль дәрәҗәдә социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен килешүле көйләүгә ярдәм итү;
- социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә карарлар проектларын, Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү, социаль тәэмин итү өлкәсендә территориаль программаларны эшләү белән бәйле мәсьәләләр буенча консультацияләр үткәрү;
- территориаль килешүнең үтәлешен контрольдә тоту, аны үтәү барышында туган каршылыкларны хәл итү, шулай ук килешүгә ирешмәгән мәсьәләләрне җайга салу.

## 4. Комиссиянең хокуклары

4.1. Комиссия хокуклы:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының икътисадый һәм социаль үсеше, территориаль килешү төзегәндә килеп туган каршылыкларны җайга салу мәсьәләләре буенча комиссия якларының эшчәнлеген координацияләү;
- территориаль килешүне эшләгәндә, гамәлгә ашырганда һәм комиссия карарларын үтәгәндә комиссия якларының мәнфәгатьләрен килештерү;
- коллектив сөйләшүләр һәм территориаль килешү проектын әзерләү барышында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өч яклы комиссиясе, тармак комиссияләре, социаль партнерлыкның башка органнары белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашырырга;
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының социаль-икътисади хәле турында территориаль килешүне үтәү барышы турындагы мәсьәләләрне карау өчен кирәкле мәгълүмат алу;
- үз эшчәнлегендә катнашу өчен экспертларны, галимнәрне һәм белгечләрне, комиссия әгъзасы булмаган башка оешма вәкилләрен чакырырга, экспертлар, галимнәр һәм белгечләр җәлеп итеп эшче төркемнәр төзергә;
- профсоюз вәкилләре һәм эш бирүчеләр катнашында Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнары үткәргән утырышларда социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен һәм аларга турыдан-туры бәйле икътисадый мөнәсәбәтләрне җайга салу мәсьәләләре буенча карау өчен тәкъдимнәр кертергә;

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнары үткәргән утырышларда катнашу өчен, шулай ук әлеге органнар тарафыннан оештырылган комиссияләр эшендә катнашу өчен үз вәкилләрен җибәрергә;

- территориаль килешү проектын әзерләү һәм төзү тәртибен, территориаль килешү төзүдә катнашмаган эш бирүчеләрне кушу тәртибен закон нигезендә билгеләргә;

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнары, территориаль һөнәри берлекләр һәм аларның берләшмәләре, комиссиядә тәкъдим ителгән эш бирүчеләрнең Территориаль берләшмәләре тарафыннан каралырга тиешле Комиссия компетенциясенә кергән мәсьәләләр буенча карарлар кабул итәргә;

- социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив-хокукый актларын эшләүдә катнаширга;

- комиссия карарларының үтәлешен контрольдә тоту.

4.2. Комиссия Комиссия регламентын эшли һәм раслый.

## 5. Комиссия Координаторы

5.1. Комиссия координаторы Татарстан Республикасы Әтнә район Советы тарафыннан комиссия якларының тәкъдимнәрен исәпкә алып билгеләнә. Координатор комиссия әгъзасы булып тормый.

5.2. Комиссия координаторы:

- Комиссия эшчәнлеген якларның координаторлары белән берлектә оештыра, утырышларда рәислек итә;

- Комиссиянең эш планнарына һәм карарларына кул куя;

- якларның позицияләрен килештерүдә, уртак карарлар эшләүдә һәм аларны гамәлгә ашыруда килешүгә ирешүдә ярдәм күрсәтә;

- Комиссия секретариаты эшенә җитәкчелек итә;

- Комиссия эшендә катнашу өчен территориаль һөнәри берлекләр һәм аларның берләшмәләре, эш бирүчеләрнең Территориаль берләшмәләре һәм Комиссия әгъзасы булмаган җирле үзидарә органнары вәкилләрен, шулай ук, кирәк булганда, галимнәрне һәм белгечләрне, башка оешма вәкилләрен чакыра;

- күрсәтелгән берләшмәләр һәм органнар үткәргән утырышларда катнашу өчен территориаль һөнәри берлекләр, эш бирүчеләрнең Территориаль берләшмәләре һәм җирле үзидарә органнары белән килешү буенча Комиссия әгъзаларын җибәрә, аларда социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салуга бәйле мәсьәләләр карала;

- Комиссия утырышлары арасында оператив карарлар кабул итүне таләп итүче мәсьәләләр буенча яклар координаторлары белән консультацияләр үткәрә;

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советына Комиссия эшчәнлеге турында хәбәр итә;

2 нче Кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә район Советының
28 апрель 2023 .№175 карарына

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының
социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча
Территориаль өч яклы комиссиясе составы

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан:**

Галиуллин Фәнис Фәрит улы – Татарстан Республикасы Әтнә район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан Территориаль өч яклы комиссия координаторы;

Гыймадиев Фердинант Илдус улы – Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы Рәисе;

Фатыйхов Рафис Рәфкать улы – Әтнә район Башкарма комитетының "Мәгариф бүлеге" МКУ начальнигы;

**Эш бирүчеләрдән:**

Мостафин Тәлгать Г. – Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Менгер» АХПК Рәисе, эш бирүчеләрдән Территориаль өч яклы комиссия координаторы (килешү буенча);

Сәфәров Рамил Рафаэль улы – "Әтнә торак-коммуналь хуҗалыгы" Муниципаль унитар предприятиесе директоры (килешү буенча);

Зиннәтуллин Илфар Әхтәм улы – «Арыш» АХППСК җитәкчесе (килешү буенча).

**Профсоюз вәкилләреннән:**

Моратова Гөлсия Радиф кызы – Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы профсоюз оешмаларының Координация советы рәисе, Россия Федерациясе дәүләт учреждениеләре һәм җәмәгать хезмәте күрсәтү хезмәткәрләренең гомумроссия һөнәри берлеге Татарстан республика оешмасының ышанычлы кешесе, профсоюз ягыннан Территориаль өч яклы комиссия координаторы;

Фәхретдинова Раилә Фоат кызы – Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләренең гомумроссия һөнәри берлегенең Әтнә территориаль оешмасы рәисе (килешү буенча);

Галәветдинова Резеда Фоат кызы – мәдәният хезмәткәрләренең һөнәри берлеге район комитеты рәисе (килешү буенча).